РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.08.2017 №165-п

*Район авыл хуҗалыгына хезмәт күрсәтү предприятиеләре коллективларының 2016 елгы эш нәтиҗәләре турында*

Район авыл хуҗалыгына хезмәт күрсәтү предприятиеләре коллективларының 2016 елгы эш нәтиҗәләрен караганнан соң,

КАРАР БИРӘМ:

1. 317 млн. 161 мең сумлык эш башкарып, авыл хуҗалыгы оешмаларына сыйфатлы сервис хезмәте күрсәткән һәм үз вакытында техника, запас частьләр белән тәэмин иткән “Сабагро” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (җитәкчесе Нигъмәтҗанов Ф.Ә.) беренче урын бирергә һәм коллективны беренче дәрәҗәдәге Диплом белән бүләкләргә.

Җитәкчегә акчалата бүләк тапшырырга һәм аеруча яхшы эшләүчеләрне бүләкләү өчен 10 мең сум күләмендә премия бүләргә.

2. Авыл хуҗалыгына 63 млн. 883 мең сумлык хезмәт күрсәткән, рентабельле эшләп, ашлыкны яхшы сыйфатлы итеп саклауга ирешкән “Шәмәрдән ашлык кабул итү предприятиесе” ачык акционерлык җәмгыятенә (җитәкчесе Вәлиев Ф.Т.) икенче урын бирергә һәм коллективны икенче дәрәҗәдәге Диплом белән бүләкләргә.

Җитәкчегә акчалата бүләк тапшырырга һәм аеруча яхшы эшләүчеләрне бүләкләү өчен 8 мең сум күләмендә премия бүләргә.

Р.Н. Минниханов